КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1515

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 сентябрь, 851 нче карары белән расланган «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып

бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 сентябрь, 851 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 сентябрь, 974 нче; 2023 ел, 22 февраль, 173 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 19 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$С_б$ – субсидия алучының эчке документы белән законнары нигезендә муниципальара маршрут өчен билгеләнгән билет бәясе (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча);».

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин